СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

01.10.2019 г.Агрыз № 34-1

2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в " пунктчасы», Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 10,11 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән уртак Тәкъдим Итәргә:

"2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган шәһәр җирлегендә яшәүче һәр кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1. Урам утларын карап тоту (светодиод яктырткычлар, ныгытма чаралары, комплектлау әйберләре сатып алу).

2. Шәһәр җирлеге чикләрендә тротуарларны карап тоту.

3. Кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы аварияле һәм коры яшел үсентеләрне сүтү (кисү).

4. Массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү (уен мәйданчыклары сатып алу).

5. Әгерҗе елгасы үзәнен төзекләндерү буенча эшләр башкару.

6. Шәһәр җирлеге территориясендә Күмү урыннарын карап тоту.

7. Төзекләндерү буенча чаралар: территорияне яшелләндерү, утырту материалы (чәчәкләр үсентеләре, газон үләне үсентесе сатып алу)

ӘЙЕ ЮК».

2. "Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында әлеге карарны урнаштырырга. http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында. http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары, «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы Рәисе урынбасары Шәймөхәммәтов И. Э. йөкләргә.

Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ